| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.01.2026 Олы Кайбыч ав. № 69

2025 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә гарантияләнгән исемлек нигезендә җирләү буенча күрсәтелүче хезмәтләр бәясен 9678,63 сум күләмендә (1 һәм 2 нче кушымталар) билгеләргә.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2026 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Н.Макаров

Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның «30» 01
69 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә гарантияләнгән исемлек нигезендә җирләү буенча күрсәтелүче хезмәтләр бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Бәясе *(сум)*** |
|---|---|
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4361,52 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 1288,70 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 4028,41 |
| **Барлыгы** | **9678,63** |

Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның «30» 01
69 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә гарантияләнгән исемлек нигезендә җирләү буенча күрсәтелүче хезмәтләр бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Бәясе** ***(сум)*** |
|---|---|
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Кәфенләү | 1010,18 |
| 3. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3506,46 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 1248,36 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 3913,63 |
| **Барлыгы** | **9678,63** |